КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 12 август

г.Казань

№ 802

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елга дәүләт яшьләр сәясәте, физик культура һәм спорт учреждениеләренең норматив чыгымнарын раслау турында» 2021 ел, 7 сентябрь, 837 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елга дәүләт яшьләр сәясәте, физик культура һәм спорт учреждениеләренең норматив чыгымнарын раслау турында» 2021 ел, 7 сентябрь, 837 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 29 гыйнвар, 71 нче, 2022 ел, 13 май, 438 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Түбәндәгеләрне расларга:

карарга теркәлгән 2022 елга дәүләт яшьләр сәясәте, физик культура һәм спорт учреждениеләренең норматив чыгымнары;

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының «Сәләт - Ак Барс» яшьләр үзәге» дәүләт автоном учреждениесенең норматив чыгымнарына карата 1,0018 тигез булган төзәтү коэффициенты.»;

әлеге карар белән расланган 2022 елга дәүләт яшьләр сәясәте, физик культура һәм спорт учреждениеләренең норматив чыгымнарына түбәндәге эчтәлекле $12^1$ пункт өстәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «$12^1$. | Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының «Сәләт - Ак Барс» яшьләр үзәге» дәүләт автоном учреждениесе | дәүләт (муниципаль) милкендәге мөлкәтне карап тоту (эксплуатацияләү) | 33 644 772,31». |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин